КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 24 ноябрь г.Казань № 902

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 12 февраль, 97 нче; 2014 ел, 10 июль, 484 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Административ регламентлар федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары нигезендә эшчәнлекләре өлкәсенә дәүләт функциясен үтәү кергән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан эшләнә.

Административ регламентны эшли башлау өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына дәүләт функцияләрен үтәү буенча вәкаләтләр бирү нигез булып тора.

Административ регламент проекты эшләнә һәм, бу Тәртипнең 3 бүлеге нигезендә бәйсез экспертиза үткәрү максатларында, «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы – административ регламент проектын эшләүченең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының рәсми сайты) урнаштырыла, шулай ук экспертиза үткәрү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына дәүләт функциясен үтәү буенча вәкаләтләр бирелгән вакыттан алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә, әгәр дә административ регламент эшләүнең башка вакытлары федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары белән билгеләнмәгән булса, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – «ТР ИСТҮ» дәүләт бюджет учреждениесе) җибәрелә.

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру кысаларында дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентлар, әгәр дә федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан тиешле регламентлар кабул ителмәгән булса, федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү регламентларына карата таләпләрне исәпкә алып эшләнә.»;

1.6 нчы пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «ТРМК ТР ИСТҮ» учреждениесе)» дигән сүзләрне «ТР ИСТҮ» дәүләт бюджет учреждениесе» дигән сүзләргә алыштырырга;

1.8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Административ регламентлар Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган көннән йә Татарстан Республикасы Президенты указы белән расланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә эшчәнлекләре өлкәсенә тиешле дәүләт функциясен үтәү кергән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырылырга тиеш.

Административ регламентлар аларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларның бердәм реестрына (алга таба – Реестр) һәм Татарстан Республикасында төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары төрләре исемлегенә (алга таба – Исемлек) кертү өчен эшчәнлекләре өлкәсенә тиешле дәүләт функциясен үтәү кергән Татарстан Республикасы дәүләт

хакимияте башкарма органнары тарафыннан административ регламент кабул ителгән көннән җиде эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына җибәрелергә тиеш.»;

1.10 нчы пунктның икенче абзацында «һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

1.11 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ регламентларга үзгәрешләр кертү бу Тәртипнең 1.6 нчы пункты нигезендә гамәлгә ашырыла. Кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган административ регламентлар Реестрга һәм Исемлеккә билгеләнгән тәртиптә һәм билгеләнгән вакытларда үзгәрешләр кертү өчен эшчәнлекләре өлкәсенә тиешле дәүләт функциясен үтәү кергән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына җибәрелергә тиеш.».

2.3 нче пунктның «г» һәм «д» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) төбәк дәүләт тикшерүендәге (күзәтчелегендәге) объектлар, төбәк дәүләт тикшерүендәге (күзәтчелегендәге) предмет;

д) төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте башкарма органының вазыйфат затлары өчен хокуклар, йөкләмәләр һәм чикләүләр;»;

2.4 нче пунктның «д» пунктчасында «дәүләт күзәтчелеген» дигән сүзләрне «дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген)» дигән сүзләргә алыштырырга;

2.4.1 нче пунктта:

«г» пунктчасында «, шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

«д» пунктчасында «, шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

2.4.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.3. Дәүләт функциясен үтәү вакытына кагылышлы бүлектә дәүләт функциясен үтәүнең гомуми вакыты һәм даимилеге, шулай ук тикшерүләр шартлары һәм аларны туктатып тору мөмкин булган вакытлары һәм аларның вакытларын озайту, Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт функциясен үтәү вакытларына кагылышлы башка мәгълүмат күрсәтелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.4 – 2.4.7 нче пунктлар өстәргә:

«2.4.4. Тикшерүләр үткәрү өчен булган нигезләргә кагылышлы бүлектә план буенча һәм планнан тыш тикшерүләрне дәүләт тикшерүенең (күзәтчелегенең) тиешле төре өчен мондый таләпләр куела торган норматив хокук актына таянып үткәрү өчен нигезләр бәян ителә.

2.4.5. Төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) үткәрүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларны билгели торган бүлектә дәүләт функциясен үтәүче дәүләт хакимияте башкарма органы вазыйфаи затларының тулы исемлеге һәм (яки)

мондый вазыйфаи затларны билгели торган норматив хокук актына (ул булган очракта) сылтама китерелә.

2.4.6. «Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законны бозган өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр җаваплылыгын билгели торган бүлектә, әлеге законның 25 статьясындагы 2 өлешнең таләпләрен исәпкә алып, үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне тиешенчә үтәмәгән өчен юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар яки юридик затларның вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре җаваплылыгың нигезләре китерелә.

2.4.7. Тикшерү үткәргәндә дәүләт функциясен үтәүче дәүләт хакимияте башкарма органының, аның вазыйфаи затларының җаваплылыгын билгели торган бүлектә, «Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау трында» Федераль законның 19 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләр таләпләрен исәпкә алып, аларның җаваплылыгы турында нигезләмәләр билгеләнә.»;

2.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бу бүлектә шулай ук «Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законның $8^2$ статьясы нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләре билгеләнә.»;

2.7 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бүлектә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карамагындагы йә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосы буйсынуындагы оешмаларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү өчен кирәкле булган һәм дәүләт хакимияте башкарма органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түләүсез нигездә, шулай ук электрон формада Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән вакытларда һәм тәртиптә соратыла һәм алына торган документларның һәм мәгълүматларның тулы исемлеге китерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин